ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МОНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423644 с.Монашево, ул.Школьная д.19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОНАШЕВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423644 , РТ, Менделеевск районы,
Монашево авылы, Мэктэп урамы
19 йорт

Тел.(885549)3-73-18 ИНН 1627005472, КПП162701001 ОКПО 93072831 ОГРН 1061674006570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.03.2025 ел № 12

Хуҗасыз хайваннарны кайтару
тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны
элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында
карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген
билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә буш урыннар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар:
-Монашево авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә, Ленин урамыннан 250 метр ераклыкта (Актаҗик авылына таба туфрак юл);
-Илнәт авылының көньяк-көнчыгыш өлеше, Крайняя урамыннан 250 метр ераклыкта (фермага таба юл);
- Актаҗик авылының көньяк өлеше, Левовозжайский урамыннан 250 метр ераклыкта (көтүлекләргә таба туфрак юл)
- Яңа Кокшан авылының төньяк өлеше, Ушковлар урамыннан 200 метр ераклыкта, көтүлекләр ягына таба);
- Татар Кокшаны авылының көньяк өлеше, Ттынычлык урамыннан 150 метр ераклыкта ( чишмәгә кадәр юл)

Әлеге территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дигән язулы табличкалар куярга.

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге башлыгы Иосифов Ростислав Феофановичны хуҗасыз хайваннарның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Монашево авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Советының
2025 елның 24 мартындагы 12 номерлы
карарына 1 кушымта

Монашево авыл җирлеге территориясендә терлекләрне хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Хайваннарны приютта стерильләштерү , тамгалау, исәпкә алу, карантинлаштыру, дәвалау, вакцинацияләү чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яисә кешегә карата мотивацияләнмәгән агрессивлык күрсәтми торган хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына ( тотылган ау урынына) кире кайтару тыела, әгәр мондый хайваннарны приютларда, һәм территориядән 500 метрдан якынрак ераклыкта тоту мөмкинлеге булмаса:

- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

- җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

- белем бирү оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

- мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

- җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектлары урнашкан урыннар.

- йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

- күпфатирлы йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, моңа күпфатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары да керә.

- Зиратлар һәм мемориаль зоналар.